Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советы

КАРАРЫ

17 июль 2018 ел №124

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре территориясендә физик затларның милкенә салым турында” 150 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2017 елның 30 сентябрендәге «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» №286-ФЗ Федераль закон, 2014 елның 30 октябрендәге «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында" №82-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы, 2018 елның 13 апрелендәге 66м номерлы Хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча бәяләмәне исәпкә алып,

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә физик затларның милкенә салым турында» 150 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2015 елның 6 маендагы №178, 2015 елның 23 октябрендәге №11 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 3 пунктчасының 4 абзацында «бер торак бина (торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырырга.

2. Район башкарма комитеты хокук идарәсе башлыгына (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU ) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны бюджет-финанс мәсьәләләре буенча шәһәр Советының даими комиссиясенә (Ф.Р. Хәмидуллин) йөкләргә.

Шәһәр башлыгы А.Р. Хәйруллин